**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СЕМИОЗЕРКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Верхняя ур., 99А, Семиозерка авылы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 420099

**СОВЕТ СЕМИОЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Верхняя ул., 99А, с. Семиозерка, Высокогорский район, Республика Татарстан, 420099

Тел.: +7 (84365) 3-29-63, e-mail: 7ozer.vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**22 май 2020 ел** **№ 249**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 12 ноябрендәге 215 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә», Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлеге Советының «Җир салымы турындам» 2019 елның 12 ноябрендәге 215 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә»:

1) 5 пунктта. «салым түләүче-оешмалар һәм» сүзләрен төшереп калдырырга»;

2) 5.1 пунктлар. 5.2 «төшереп калдырырга»;

3) 7.1 пунктының 4 абзацындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ташламаны бирү өчен нигез булып, Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгы яисә сугышта катнашучы таныклыгы, күрсәтелгән ташламаны алу хокукын раслаучы башка тиешле документлар тора».

4) 3 пунктны 3.1.1 пункт белән киләсе эчтәлектәк белән тулыландырырга:

«3.1.1. Салым түләү салым түләүчеләр тарафыннан җир кишәрлекләре урнашкан урын буенча башкарыла.

Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү беренче, икенче һәм өченче квартал узганнан соң җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасы ¼ күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.»

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3 Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Р.Р.Гусамов